ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ

423190, с. Новошешминск, ул. Ленина, 37 «А»
тел. (факс): 8(84348) 2-25-47, 8(84348) 2-27-67

423190,Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 37 "А"
тел. (факс): 8(84348) 2-25-47, 8(84348) 2-27-67

тел.факс.: (8-84348) 2-25-47, тел.факс: (8-84348) 2-27-67, Pizo.Nsm@tatar.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

2024 елның 11 мартыннан №181

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 февралендәге 89 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боерык бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 февралендәге 89 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 февралендәге 88 номерлы боерыгы белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.2.1 пунктындагы 8 пунктчасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«төзелгән территорияне үстерү» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Милек һәм җир палатасы рәисе Н. В. Попкова